| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СОСНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>СОСНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 81

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы,Сосна авыл җирлеге Уставының 11 статьясы,Сосна авыл җирлеге Советының 2018 елның №80 «Сосна авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын, Сосна авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 сентябрендәге «Сосна авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында " гы 15 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда референдумда тавыш бирү хокукына ия булган 18 яше тулган Сосна авыл җирлегенең һәр кешесеннән 600 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, су белән тәэмин итүне капиталь ремонтлау проектын эшләү, Түбән Сосна авылында агач кисү

**ЭЙЕ** **ЮК**».

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым юнәлешләр буенча алынган акчалар экономиясе барлыкка килгән очракта, Сосна авыл җирлеге Советы

карары нигезендә, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрелә.

4. Әлеге карарны  Хезмәт» район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга pravo.tatarstan.ru  Сосна авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк baltasi.tatarstan.ru

5. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов